СОВЕТ КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гагарина, д.29, с.Куюк-Ерыкса,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Гагарин ур., 29 нче йорт, Көек-Ерыкса авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422151

тел.(факс): (85563) 3-67-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

17 сентябрь 2018 ел | №5-34

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 апрелендәге 2-33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131 -ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 апрелендәге 2-33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 пунктын (үзара салым акчаларын җыю тәртибе) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзара салым акчаларын җыю тәртибе җирлекнең хокукый акты белән билгеләнә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге башлыгы Ф.Р.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Ф.Р.Шәйхетдинов/